**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 август № 597

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау комплекслы системасын үстерү» ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 июнь, 492 нче, 2014 ел, 25 сентябрь, 678 нче, 2014 ел, 9 декабрь, 962 нче, 2014 ел, 31 декабрь, 1090 нчы, 2015 ел, 2 февраль, 54 нче; 2015 ел, 24 апрель, 279 нчы; 2015 ел, 7 август, 576 нчы; 2015 ел, 24 август, 619 нчы, 2015 ел, 26 август, 620 нче; 2015 ел, 16 октябрь, 771 нче; 2015 ел, 11 ноябрь, 844 нче; 2016 ел, 19 гыйнвар, 19 нчы; 2016 ел, 11 февраль, 85 нче; 2016 ел, 30 апрель, 274 нче; 2016 ел, 14 май, 315 нче; 2016 ел, 25 май, 346 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау комплекслы системасын үстерү» ярдәмче программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау комплекслы системасын үстерү» ярдәмче программасы паспортында «Еллар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка

ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 6 нчы ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 6 нчы ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 2020 елга 6 нчы ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2013 ел белән чагыштырганда түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре санын 92 процентка кадәр киметергә;<br>судка кадәрге тәртиптә җайга салынган кулланучылар низагларының чагыштырма авырлыгын 113 процентка кадәр арттырырга;<br>кулланучылар үзләренең хокукларын яклау мәсьәләләре буенча алган консультацияләр санын 112 процентка кадәр арттырырга;<br>кулланучылар хокукларын яклау турында законнар таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча семинарлар тыңлаган хуҗалык итүче субъектлар санын 113 процентка кадәр арттырырга;<br>республика массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылган кулланучылар хокукларын яклау мәсьәләләренә кагылышлы материаллар санын 114 процентка кадәр арттырырга;<br>кулланучылар хокукларын яклау турында законнар нигезләре буенча дәресләрдә катнашкан республика мәгариф учреждениеләре укучылары санын 113 процентка кадәр арттырырга;<br>нәтиҗәләрен алга таба массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып, республика кулланучылар базарында реализацияләнә торган товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) тикшеренүләр һәм экспертизалар санын 120 процентка кадәр арттырырга»; |

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау комплекслы системасын үстерү» ярдәмче программасына теркәлгән кушымтада:

2.1 нче пункттагы 16 – 19 графаларда «0,7» саннарын «0,6» саннарына алмаштырырга;

2.9 нчы пунктта:

9, 10 нчы графаларда «111» саннарын «112» саннарына алмаштырырга;

11 графада «111» саннарын «113» саннарына алмаштырырга;

12 графада «112» саннарын «114» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.12. Кулланучылар хокукларын яклау мәсьәләләренә бәйле тармак һөнәри, рейтинг конкурсларын ел саен үткәргә | ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе, ТР буенча Роспотребнадзор идарәсе (килешү буенча), ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССУ (килешү буенча), иҗтимагый оешмалар (килешү буенча) | 2017 – 2020 еллар | | | | | | | | | | | | | 0,1 | 0,1 | 0,1 | 0,1». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков